**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, поселогы,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 29.11.2023** **№1829**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүматитехник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 7 апрелендәге 398 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүматитехник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 7 апрелендәге 398 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2 пункты 3, 4, 5 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«база оклады (база вазыйфаи оклады), хезмәт хакының база ставкасы - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче һөнәре яисә хезмәткәр вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы дәүләт яисә муниципаль

учреждение хезмәткәренең минималь оклады (вазыйфаи окладны), хезмәт хакы ставкасы;

оклад (вазыйфаи оклад) - компенсация, стимуллаштыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, календарь ай өчен билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәргә хезмәт хакының билгеләнгән күләме;

хезмәт хакы (хезмәткәр хезмәтенә түләү) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарган эшенең катлаулылыгына, күләменә, сыйфатына һәм шартларына бәйле рәвештә хезмәте өчен түләү, шулай ук компенсация түләүләре (компенсация характерындагы, шул исәптән нормаль шартлардан читкә тайпылган шартларда, махсус климат шартларында һәм радиоактив пычрануга дучар булган территорияләрдә эшләгән өчен өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, һәм компенсацияләү характерындагы башка түләүләр) һәм стимуллаштыру түләүләре (стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре);»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча, һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә):

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин